**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№140** **«28» май 2019 ел**

**«Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтен оештыру һәм хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә хакында»**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтен оештыру һәм хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карар 2019 елның 01 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Штат расписаниеләрен һәм локаль актларны әлеге нигезләмәгә туры китерергә.
4. Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе**
**авыл җирлеге башлыгы** **Н. Ә. Гатина**

Зәй муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге Советының
2019 елның 28 маендагы
140 номерлы карары белән
расланган.

**Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтен оештыру һәм хезмәт өчен түләү шартлары турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтен оештыру һәм хезмәт өчен түләү шартлары турында әлеге нигезләмә бухгалтерлар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

## 2. Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры хезмәтенә түләү

2.1. Бухгалтерның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүдән, акчалата бүләкләүдән, еллык түләүле отпуск алганда матди ярдәмнән һәм бер мәртәбә бирелә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

2.2. Бухгалтерның вазыйфаи окладı түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Вазыйфа** | **Түбәндәге халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары** | |
|---|---|---|
| | **3,5 меңгә кадәр кеше** | **3,5 меңнән артык кеше** |
| Баш бухгалтер | 15 700 сум | 17 000 сум |

| | | |
|---|---|---|
| Бухгалтер | - | 14 500 сум |

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының штат расписаниесенә бухгалтер вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык булу тора.

2.3. Бухгалтерларга:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен түбәндәге күләмдә өстәмә түләү билгеләнә:

| Түбәндәге эш стажы булганда | Айлык өстәмә түләү, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) еллык түләүле отпуск алганда вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү;

Календарь ел дәвамында бухгалтерга еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, бер тапкыр бирелә торган түләү исәпләнеп, декабрь аенда эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә, ә эштән киткән очракта соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

Беренче эш елында еллык түләүле отпуск биргәндә бухгалтерга бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләп түләнә. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән башлап агымдагы елның 31 декабрен кертеп исәпләнә.

5) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм;

6) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премия (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми).

2.4. Бухгалтерга һөнәрләрне бергә алып барганда, хезмәт күрсәтү зоналары киңәйгәндә һәм, үзенең төп эше белән беррәттән, вакытлыча булмаган хезмәткәрнең эшен алып барганда хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә төп эш буенча вазыйфаи окладның 50 проценты күләмендә өстәмә түләү билгеләргә.

2.5. Бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен хезмәткәргә түләү тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәне, эшнең интенсивлыгын, акчалата бүләкләүне исәпкә алып, биләгән вазыйфа буенча икеләтә вазыйфаи оклад күләмендә башкарыла.

2.6. Билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында хезмәткәрләргә юбилей, никахлашу, бала туу, уллыкка (кызлыкка) бала алу, ире (хатыны), балалары, ата-аналары вафат булу уңаеннан бер тапкыр матди ярдәм күрсәтелергә мөмкин.

2.7. Бухгалтерларның хезмәт хакының еллык фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \mathrm{P} * (1 + t);$$

биредә:

$FOT$ – бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ - бухгалтерга вазыйфаи окладын түләүгә акча суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле елларны эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләүгә, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпускны биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү, матди ярдәм күрсәткән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүгә акчалар суммасы;

Р – бухгалтерларның еллык премия фонды (әлеге нигезләмәнең 2 пункты 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә торган);

$n$– бухгалтерларның штаттагы саны

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт өчен түләү буенча исәпләүләр.

## 3. Хезмәткәрләргә башка өстәмә түләүләр

3.1. Эш бирүче (яллаучы вәкиле) хезмәткәрләргә гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә башка өстәмә түләүләр түләргә хокуклы.